ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ӨСКЕБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

19 август 2019 ел №14

Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы 2014 елның 25 нче гыйнвары 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара районы прокурорының 2019 елның 14 июнендәге 02-01-22-2018 номерлы, ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатыннан, норматив хокукый актны үзгәртү турындагы таләбен карап, Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган ( Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 34 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 16 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту Кагыйдәләре белән территориаль зоналарны яисә аларның өлешләрен өстәмә юнәлешләр буенча куллануга аерым шәһәр төзелеше таләпләре билгеләнә:».

Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов